# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасында дәүләт милкен һәм коммуналь милекне үзгәртеп кору (дәүләттән аеру һәм хосусыйлаштыру) турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

<u>1 статья.</u> "Татарстан Республикасында дәүләт милкен һәм коммуналь милекне үзгәртеп кору (дәүләттән аеру һәм хосусыйлаштыру) турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы җыелма басмасы, 1992, N 4), түбәндәгечә бәян итеп, үзгәрешләр һәм әстәмәләр кертергә:

"Татарстан Республикасында дәүләт
мөлкәтен хосусыйлаштыру турында

Татарстан Республикасы
З А К О Н Ы

Әлеге Закон Татарстан Республикасында республика милкендәге (республика мөлкәтен), коммуналь милектәге (коммуналь мөлкәтне) дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның оештыру һәм хокукый нигезләрен, хосусыйлаштыру тәртибен билгели һәм эшкуарлык эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыруга, социаль юнәлешле базар икътисадын булдыруга юнәлтелгән.

## I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру төшенчәсе

Әлеге Закон максатларыннан чыгып караганда, дәүләт мөлкә-

тен хосусыйлаштыру дәүләт (республика һәм коммуналь) милкендәге мөлкәтне (хосусыйлаштыру объектларын) физик һәм юридик затлар милкенә бушлай аерып бирүне аңлата.

<u>2 статья.</u> Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруны хокукый җайга салу

Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруны хокукый җайга салу әлеге Закон һәм аның нигезендә кабул ителүче Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

<u>3 статья.</u> Әлеге Законның гамәлдә булу өлкәсен чикләү

1. Әлеге Закон түбәндәгеләргә кагылмый:

Татарстан Республикасының физик һәм юридик затлар белән уртак милектә булган мөлкәтен хосусыйлаштыруга;

милекчеләрнең, аларның варисларының һәм хокук дәвамчыларының ихтыярларына каршы килеп национализацияләнгән, конфискацияләнгән яисә башка ысул белән дәүләт милкенә тартып алынган мөлкәти хокукларын торгызуга;

җирләрне хосусыйлаштыруга;

табигый байлыкларны хосусыйлаштыруга;

торак фондын хосусыйлаштыруга;

дәүләт резервын хосусыйлаштыруга;

дәүләт унитар предприятиеләренә һәм учреждениеләренә хуҗалык итү яисә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәт белән эш иткәндә барлыкка килүче мөнәсәбәтләргә;

халыкара шартнамәләр һәм Россия Федерациясе, аның субъектлары белән шартнамәләр буенча Татарстан Республикасы йөкләмәләрен үтәү очракларына.

2. Әгәр чит ил инвестицияләре турындагы законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, чит ил юридик затларының һәм гражданнарының хосусыйлаштыруда катнашуы әлеге Закон белән җайга салына.

3. Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив-хокукый актларда хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә алынган мөлкәтне сатып алуга суммар квоталар, шулай ук мөлкәтне алып са-

туга һәм башкача аерып алуга вакытлыча тыю билгеләнергә мөмкин.

4 статья. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә милекчелек хокукы алучы субъектлар (сатып алучылар)

1. Дәүләт мөлкәте субъектларын хосусыйлаштырганда дәүләт (республика һәм коммуналь) предприятиеләре, казна предприятиеләре, дәүләт учреждениеләре, шулай ук устав (тупланма) капиталларында (мөлкәтендә) дәүләт өлеше 25 процентган артыграк булган башка юридик затлар милекчелек хокукы алучы субъектлар (сатып алучылар) була алмыйлар.

2. Дәүләт мөлкәтен сатып алу хокукы булуын исбатлау вазыйфасы сатып алучының үзенә йөкләнә. Дәүләт мөлкәтен дәүләттән аерып алу мизгеленә сатып алучының аны сатып алу өчен законлы хокуклары булмаса, алыш-биреш килешүе законнар нигезендә гамәлгә яраксыз дип таныла.

3. Сатып алучылар тапшыручы документлар исемлеге һәм аларны тапшыру тәртибе әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаучы нигезләмә белән билгеләнә.

5 статья. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруны гамәлгә ашыручы вәкаләтле органнар

1. Республика милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруны Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт комитеты (алга таба - Дәүләт комитеты); коммуналь милектәге мөлкәтне хосусыйлаштыруны Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарының коммуналь мөлкәт белән идарә итү комитетлары (алга таба - җирле комитетлар) үз вәкаләтләре нигезендә гамәлгә ашыралар.

2. Дәүләт комитеты үз вәкаләтләре чикләрендә республика милкенә карата дәүләт мәнфәгатьләрен чагылдыра, республика милкендәге мөлкәтне законнар нигезендә били, аннан файдалана һәм аның белән эш итә.

Дәүләт Комитеты республика мәлкәтен хосусыйлаштыру буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны җирле комитетлар-

га тапшырырга хокуклы.

Дәүләт комитеты Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган нигезләмә нигезендә эш итә.

3. Законнар нигезендә дәүләт комитеты:

үз вәкаләтләре чикләрендә әлеге Законда, башка законнарда, Хосусыйлаштыру буенча дәүләт программасында каралган һәм хосусыйлаштыру процессларын һәм дәүләт мөлкәте белән эш итүне җайга салучы норматив-хокукый актлар әзерли һәм чыгара, әлеге норматив-хокукый актларның үтәлешен тикшереп тора, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертә, шулай ук хосусыйлаштыру турында Татарстан Республикасы законнарын куллану турындагы аңлатмалар бирә;

хосусыйлаштыру барышында тәзелүче ачык акционер җәмгыятьләрнең Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә куючысы була;

акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) республика милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләренең акционеры (катнашучысы) хокукларын Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашыра

хосусыйлаштыру комиссияләре төзи;

хосусыйлаштырганда законнар нигезендә ташламалар бирә;

республика милкендәге мөлкәтне, шул исәптән өлешләрне (пайларны), акцияләрне сатучы була;

хосусыйлаштырылган мөлкәтне сатып алучыга аның тарафыннан сату-алу шартнамәсенең түләү буенча шартлары, шулай ук социаль һәм инвестиция шартлары үтәлгәннән соң Татарстан Республикасының дәүләт милкен хосусыйлаштыру актларының дәүләт реестрында хосусыйлаштыру актын теркәү турында таныклык (алга таба - хосусыйлаштыру турында таныклык) бирә;

җирле комитетларга методик җитәкчелек итә һәм эшчәнлекләрен тикшереп тора;

республика мөлкәтен хосусыйлаштыру барышында төзелгән, устав (тупланма) капиталында дәүләт өлеше 50 процент һәм аннан да күбрәген тәшкил иткән ачык акционер җәмгыятьләргә мөлкәтне дәүләттән аерып алуга һәм аның белән башкача эш итүгә, шул исәптән әлеге Законның 8 статьясы нигезендә ачык акционер җәмгыятьләрнең хокукый хәле үзенчәлекләренең гамәлдә булу чорына мөлкәти кертемнәрне залогка салу, арендалау һәм оешмаларның устав (тупланма) капиталына кертү билгеләнгән тәртиптә рөхсәт ителә.

4. Дәүләт комитеты Татарстан Республикасының Республика бюджеты акчалары исәбеннән финанслана.

Хосусыйлаштыру һәм фонд базарын үстерү мәсьәләләре буенча, шулай ук эшчәнлегенең башка юнәлешләре буенча Дәүләт комитеты тарафыннан уздырылучы гамәлләр Татарстан Республикасының хосусыйлаштыру фонды акчалары исәбеннән финанслана.

5. Үз вәкаләтләре чикләрендә җирле комитет коммуналь милектәге мөлкәтне законнар нигезендә били, аннан файдалана һәм аның белән эш итә.

Җирле комитет коммуналь милекне идарә итү турындагы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаучы бердәм нигезләмә буенча әзерләнүче нигезләмәгә таянып эшли. Җирле комитет турындагы нигезләмә тиешле район (шәһәр) администрациясе башлыгы тарафыннан раслана.

Җирле комитет:

Дәүләт программасы нигезләмәләрен исәпкә алып эшләнгән коммуналь мөлкәтне хосусыйлаштыру программасының проектын килештерү өчен Дәүләт комитетына тәкъдим итә;

хосусыйлаштыру барышында төзелүче ачык акционер җәмгыятьләрнең законнар нигезендә гамәлгә куючысы була;

акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) коммуналь милектә булган хуҗалык җәмгыятьләренең акционеры (катнашучысы) хокукларын гамәлгә ашыра;

хосусыйлаштыру комиссияләре төзи;

хосусыйлаштырганда законнар нигезендә ташламалар бирә;

коммуналь милектәге коммуналь мөлкәтне, өлешләрне (пайларны), акцияләрне сатучы була.

Җирле комитетлар җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслана. Хосусыйлаштыру һәм фонд базарын үстерү мәсьәләләре буенча, шулай ук алар эшчәнлегенең башка юнәлешләре буенча җирле комитетлар тарафыннан уздырылучы гамәлләр - тиешле хосусыйлаштыру фондларыннан, ә алар булмаганда - коммуналь мөлкәтне хосусыйлаштырудан (һәм алар белән башкача эш итүдән) алынган, җирле комитетларның махсус счетларында тупланучы акчалар исәбеннән финанслана.

Җирле комитетларның эшчәнлеген Дәүләт комитеты тикшереп тора.

6 статья. Хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыятьләргә карата дәүләт вәкаләтләре

1. Татарстан Республикасының иминлеген, дәүләт мөлкәтен нәтиҗәле файдалануны, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында дәүләт предприятиеләрен ачык акционер җәмгыятьләргә үзгәртеп корганда яисә республика милкендәге ачык акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен сату турында карар кабул иткәндә Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм Дәүләт комитеты күрсәтелгән ачык акционер җәмгыятьләргә карата күрсәтелгән ачык акционер җәмгыятьләрне идарә итүдә Татарстан Республикасының катнашуына махсус хокук ("алтын акция") куллану турында карарлар кабул итә алалар.

2. Махсус хокук ("алтын акция") куллану турында карар кабул иткән Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм Дәүләт комитеты директорлар советына (күзәтчелек советына) һәм ачык акционер җәмгыятьнең ревизия комиссиясенә дәүләт вәкилләрен (ревизор) билгелиләр

3. Үзенә карата махсус хокук ("алтын акция") куллану турында карар кабул ителгән ачык акционер җәмгыять акционерларының гомуми җыелышын, директорлар советы утырышын уздыру вакытлары һәм тәкъдим ителүче көн тәртибе турында дәүләт вәкилләренә законнарда билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә тиеш.

4. Хосусыйлаштыру барышында төзелгән махсус хокуктан ("алтын акция"дән) файдалану турында карар кабул ителгән ачык акционер җәмгыятьләрдә дәүләт вәкилләре җәмгыятькә идарә итүнең коллегиаль органнары эшчәнлегендә катнашалар, акционерларның еллык гомуми җыелышы көн тәртибенә тәкъдимнәр кертергә хокуклылар, шулай ук акционерларның гомуми җыелышы йә директорлар советы (күзәтү советы) тарафыннан (әгәр каралучы мәсьәләләр җәмгыятьнең вәкаләтләренә керсә) түбәндәге карарлар кабул ителгәндә, вето хокукына ия булалар:

уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү яисә уставны яңа редакциядә раслау турында;

җәмгыятьне үзгәртеп кору турында;

җәмгыятьне бетерү, бетерү комиссиясен билгеләү һәм ике арадагы һәм иң соңгы бетерү балансларын раслау турында;

устав капиталы күләмен үзгәртү турында;

холдинг компанияләрендә, финанс-сәнәгать төркемнәрендә, коммерция оешмаларының башка берләшмәләрендә җәмгыятьнең катнашуы турында;

"Акционер җәмгыятьләр турында"гы Федераль закон нигезендә эре алыш-биреш килешүләре һәм кызыксынырлык алыш-биреш килешүләре төзү турында.

5. Дәүләт вәкилләре ачык акционер җәмгыятьнең барлык документларын соратып алырга хокуклылар һәм хезмәт, коммерция серен чишкән өчен җаваплы булалар, шулай ук җәмгыятьнең кыйммәтле кәгазьләрен биләүчеләрнең күрсәтелгән реестрда теркәлгән исеме (атамасы) турындагы, аларныкы булган кыйммәтле кәгазьләрнең саны, категориясе (тибы), номиналь хакы турындагы белешмәләрне ачык акционер җәмгыятьнең кыйммәтле кәгазьләр реестрын тотучыдан соратып алырга хокуклылар.

6. Дәүләт вәкилләре ачык акционер җәмгыятьнең директорлар советы (күзәтчелек советы) әгъзасына, ачык акционер җәмгыятьнең шәхсән үзе генә җитәкчелек итә торган башкарма органына (директорына, генераль директорына), ачык акционер җәмгыятьнең коллегиаль башкарма органы (идарәсе, директорлыгы) әгъзасына, шулай ук оешма идарәчесенә (идарәчегә) карата "Акционер җәмгыятьләр турында"гы Федераль закон нигезендә зыянны түләттерү турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7. Дәүләт вәкилләре ачык акционер җәмгыятьнең директорлар советы (күзәтчелек советы) әгъзалары булалар. Директорлар советы (күзәтчелек советы) әгъзаларын сайлаганда дәүләт вәкилләренең директорлар советындагы (күзәтчелек советындагы) урыннары исәпкә алынмый.

Дәүләт вәкилләре - директорлар советы (күзәтчелек советы) әгъзалары законнарда каралган хокукларга һәм бурычларга ия.

8. Махсус хокуктан ("алтын акция"дән) файдаланучы дәүләт вәкилләре итеп үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган норматив-хокукый актлар нигезендә башкаручы дәүләт хезмәткәрләре билгеләнә.

9. Махсус хокукларның ("алтын акция"нең) гамәлдә булуын туктату турында карарны аны гамәлгә кертү турындагы карарны кабул иткән орган кабул итә. Махсус хокук ("алтын акция") аны туктату турында карар кабул иткәнче гамәлдә була.

10. Махсус хокук ("алтын акция") үзенә карата әлеге хокукны куллану турында карар кабул ителгән ачык акционер җәмгыятьнең акцияләренә алыштырылмый.

7 статья. Акцияләре дәүләт милкендә беркетелгән ачык акционер җәмгыятьләрдә Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен чагылдыру

Татарстан Республикасы иминлеген тәэмин итү, дәүләт мөлкәтеннән нәтиҗәлерәк файдалану, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы районнарының һәм шәһәрләренең администрацияләре, җирле комитетлар хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен дәүләт милкенә беркетү турында карар кабул итәргә һәм әлеге акционер җәмгыятьләрнең идарә органнарында дәүләт хезмәткәрләре арасыннан дәүләт вәкилләрен норматив-хокукый актлар нигезендә билгеләргә мөмкин.

8 статья. Хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыятьләрнең хокукый хәле үзенчәлекләренең гамәлдә булу тәртибе

1. Татарстан Республикасында хосусыйлаштыру барышында барлыкка килгән ачык акционер җәмгыятьләрнең әлеге Законда һәм башка норматив-хокукый актларда каралган хокукый хәле үзенчәлекләре җәмгыятьне теркәгән көннән башлап аларга тиешле акцияләрнең 75 процентын дәүләт тарафыннан аерып алынган мизгелгә кадәр гамәлдә була.

2. Дәүләт мәнфәгатьләрен яклау максатларында, устав капиталындагы дәүләт өлеше 25 процент һәм аннан да күбрәк булган ачык акционер җәмгыятьләр акцияләр эмиссияләүне бары тик Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән шартларда гына гамәлгә ашыра алалар.

3. Хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыятьләрнең хокукый хәле үзенчәлекләренең гамәлдә булу чорында

акционерларның устав капиталында дәүләт өлеше 25 проценттан да кимрәк булган ачык акционер җәмгыятьләрнең гомуми җыелышларында директорлар советы (күзәтчелек советы) әгъзаларын сайлаганда тавыш бирү тәртибе Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә.

## II бүлек. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм ысуллары

### 9 статья. Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру буенча дәүләт программасы, коммуналь мөлкәтне хосусыйлаштыру программалары

Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру буенча дәүләт программасы (алга таба - Дәүләт программасы) дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруны уздыруның максатларын, тәртибен, өстенлекләрен, хосусыйлаштырылмаска тиешле объектларның исемлеген билгели.

Дәүләт программасында билгеләнгән нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең барлык органнары һәм җирле администрацияләр тарафыннан үтәү мәҗбүри.

Дәүләт программасы якындагы өч елга эшләнә. Дәүләт программасы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

Хосусыйлаштыруның җирле программалары законнар нигезендә бер елга эшләнә һәм аңа хосусыйлаштырылырга тиешле коммуналь мөлкәт исемлеге кертелә.

### 10 статья. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру буенча карарлар кабул итү һәм документлар тапшыру тәртибе

1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру иницативасына түбәндәгеләр ия булырга мөмкин:

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты;

Дәүләт комитеты һәм җирле комитетлар;

дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле башка органнары;

юридик һәм физик затлар, шул исәптән законнар нигезендә оешмаларның хезмәт коллективлары.

2. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы карар Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләренең администрацияләре, җирле комитетлар тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

3. Хосусыйлаштыруда катнашу өчен сатып алучылар - юридик затлар үзләренең билгеләнгән тәртиптә расланган гамәлгә кую документларының таныкланган нөсхәләрен, хуҗалык җәмгыятендә һәм ширкәтендә катнашучыларның составы һәм устав капиталын бүлү структурасы турында белешмәләр, соңгы өч еллык эшчәнлекнең баланс хисапларын, шулай ук салым инспекциясе белешмәләрен тапшыралар. Сатып алучылар - юридик затлар тарафыннан салым инспекциясе белешмәләре хезмәт әчен түләүнең Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән ике мең ярым минималь күләменнән артыграк суммага сату-алу алыш-бирешләре кылынган очракта тапшырыла һәм сатып алучылар - физик затлар тарафыннан - хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән биш йөз минималь күләменнән артыграк суммага алыш-бирешләр кылынган очракта тапшырыла.

Дәүләт (республика һәм коммуналь) мөлкәтен хосусыйлаштыру турында гариза Дәүләт комитетына һәм җирле комитетларга кертелә.

Гариза рәвеше Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Хосусыйлаштыру турында билгеләнгән тәртиптә бирелгән гаризалар теркәлгән мизгелдән бер ай эчендә Дәүләт комитеты һәм җирле комитетлар тарафыннан каралырга тиеш. Хосусыйлаштыру турындагы яисә хосусыйлаштырудан баш тарту турындагы карар гариза биргән юридик һәм физик затларга язма рәвештә җиткерелә.

5. Түбәндәге очракларда хосусыйлаштырудан баш тартырга мөмкин:

гаризада күрсәтелгән мөлкәтне хосусыйлаштыруга законнарда билгеләнгән чикләүләр булса;

гаризада күрсәтелгән мөлкәт дәүләт милкендә булмаса;

гариза биргән юридик зат әлеге закон нигезендә дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә милекчелек хокукын алучы субъект була алмаса.

Хосусыйлаштыру объектлары урнашкан җир кишәрлегеннән даи-

ми рәвештә (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукына документлар булмаган очракта яисә хосусыйлаштыру гаризасында күрсәтелгән мөлкәт Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка законнар нигезендә аерып алынырга тиеш булса, шулай ук дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырудан баш тартырга мөмкин.

6. Хосусыйлаштырылмаска тиешле предприятиеләрдә махсус продукция чыгару (хезмәт күрсәтү) белән бәйле булмаган аерым житештерүләрнең мөлкәте Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары буенча хосусыйлаштырылырга мөмкин. Мондый мөлкәтне сатып алучыларга салым ташламалары бирелергә мөмкин.

7. Дәүләт комитеты (җирле комитет) хосусыйлаштыру турында карар кабул иткәндә:

хосусыйлаштыру комиссиясе (алга таба - комиссия) төзи һәм хосусыйлаштыру планын әзерләү вакытын билгели, ул вакыт хосусыйлаштыру турында карар кабул ителгән көннән алты айга кадәр билгеләнә, кирәк чакта ул тиешле орган тарафыннан бер елга кадәр озайтылырга мөмкин.

Комиссия Татарстан Республикасында дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру комиссиясе турында Дәүләт комитеты тарафыннан раслаучы нигезләмә нигезендә эш итә.

8. Комиссия составына халык депутатлары, Дәүләт комитеты һәм (яисә) җирле комитетлар вәкилләре, администрацияләрнең һәм оешмаларның хезмәт коллективлары вәкилләре, финанс органнары вәкилләре керә. Комиссия составына министрлыкларның, дәүләт комитетларының, ведомстволарның һәм һөнәр берлекләренең вәкилләре керергә мөмкин. Комиссия үз эшенә экспертларны, махсуслаштырылган аудитор, консультация оешмаларын һәм башка оешмаларны җәлеп итәргә хокуклы.

9. Комиссия хосусыйлаштыру планын төзи, ул Дәүләт комитеты яисә җирле комитет тарафыннан раслана.

Әгәр хосусыйлаштыру комиссиясе хосусыйлаштыру планын билгеләнгән вакытка тапшырмаса, Дәүләт комитеты (җирле комитет) әлеге комиссияне таркатып яңасын оештырырга хокуклы.

10. Оешма җитәкчесе төзелгән комиссия эшчәнлеге өчен шартлар тәэмин итәргә: тиешле документларны бирергә, кирәкле белгечләрне эшкә җәлеп итәргә тиеш.

Хосусыйлаштыру планы хосусыйлаштыру ысулларын һәм вакытларын, мөлкәтнең куелган хакын яисә акционер җәмгыятьнең устав

капиталы күләмен, түләүнең (исәп-хисапларның) тәкъдим ителүче рәвешен күздә тотарга тиеш. Хосусыйлаштыру планына юридик затны үзгәртеп кору проекты, шул исәптән аның бүлекчәләрен мөстәкыйль юридик затлар итеп бүлеп чыгаруны (аларның устав капиталларын билгеләп) күздә тотучы проект та керергә мөмкин.

11. Хезмәт коллективы инициативасы буенча мөлкәтне хосусыйлаштырганда хезмәт коллективы аңа хосусыйлаштыру планы бирелгән көннән башлап бер ай эчендә Дәүләт комитетына яисә җирле комитетларга тәкъдим ителгән план буенча үз фикерен язма рәвештә җиткерергә тиеш.

Күрсәтелгән план дәлилләнеп кире кагылганда, комиссия бер ай эчендә планның икенче вариантын тәкъдим итәргә тиеш. Хосусыйлаштыру планы хезмәт коллективы тарафыннан кабат кире кагылган чакта, аны раслау турындагы карарны Дәүләт комитеты яисә җирле комитет кабул итә.

12. Хосусыйлаштыру планын да кертеп, хосусыйлаштыру тәртибе һәм ысуллары турында Дәүләт комитеты һәм җирле комитетларның карарына карата физик һәм (яисә) юридик затлар тарафыннан суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

<u>11 статья.</u> Предприятиене хосусыйлаштыруга әзерләү

Предприятиене хосусыйлаштыруга әзерләгәндә аның мөлкәте инвентарлаштырыла, күздә тотылган керемне исәпкә алып, хосусыйлаштырылучы мөлкәти комплексның, шул исәптән аның җитештерү фондларының һәм җитештерүгә кагылышы булмаган фондларының бәяләү хакы билгеләнә, финанс һәм хуҗалык хәленә, үсеш перспективасына анализ ясала.

Предприятиене хосусыйлаштыруга әзерләү барышында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы районнарының һәм шәһәрләренең администрацияләре, җирле комитетлар карары буенча ул үзгәртеп корылырга мөмкин, шул исәптән аның составыннан бер яисә берничә юридик затны бүлеп чыгару юлы белән дә.

Предприятиене хосусыйлаштыруга әзерләү барышында социаль инфраструктура объектлары составын һәм алардан файдалану тәртибе билгеләнә. Соңгылары законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнарына, хосусыйлашты-

рылган предприятиегә яисә башка затларга тапшырылырга мөмкин.

Предприятиене мөлкәти комплекс буларак хосусыйлаштырганда, хосусыйлаштыру планын раслау мизгеленнән акцияләргә ябык язылу нәтиҗәләрен раслау мизгеленә кадәр предприятиенең, Дәүләт комитеты (җирле комитет) ризалыгыннан башка, бәясе соңгы баланс хисабын раслаган көндә активларының баланс кыйммәтеннән 10 процентка артып киткән күчемле мөлкәт буенча алыш-бирешләр кылырга хакы юк.

Бу чорда күчемсез мөлкәтне аерып алу һәм залогка салу рөхсәт ителми.

12 статья. Хосусыйлаштырылырга тиешле объектлар турында мәгълүмат

1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында мәгълүмат, шул мөлкәтне сату көненә кадәр кимендә бер ай кала, мөлкәтне сатучылар тарафыннан массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга тиеш.

Коммуналь милек объектларын хосусыйлаштырганда җирле комитет тарафыннан вакыт әзрәк тә билгеләнергә мөмкин, әмма ул ике атнадан да кимрәк булмаска тиеш.

Күрсәтелгән хәбәрләрне бастырып чыгару чыгымнары тиешле хосусыйлаштыру фондлары акчаларыннан түләнә.

Хосусыйлаштыру объектларын сатканда массакүләм мәгълүмат чараларында һичшиксез бастырылып чыгарылырга тиешле белешмәләрнең исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

13 статья. Хосусыйлаштыру ысуллары

1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырганда түбәндәге хосусыйлаштыру ысуллары кулланыла:

дәүләт мөлкәтен (предприятиене мөлкәти комплекс буларак кертеп) сату, шул исәптән конкурс буенча һәм аукционда сату;

хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен сату;

акцияләренең 100 проценты да дәүләт милкендә булган дәүләт (республика һәм коммуналь) предприятиеләрен хуҗалык җәмгы-

ятьләренә, шул исәптән ачык акционер җәмгыятьләргә үзгәртеп кору;

арендаланган дәүләт мөлкәтен сатып алу;

дәүләт мөлкәтен хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларына кертем сыйфатында кертү;

Татарстан Республикасы Президенты Указлары белән билгеләнүче башка ысуллар.

2. Хосусыйлаштыру ысулын сайлаганда түбәндәгеләр исәпкә алына:

Дәүләт комитетына һәм җирле комитетларга бирелгән дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру гаризаларындагы тәкъдимнәр;

оешманың финанс хәле;

хосусыйлаштыру объектларының базар бәясе;

хосусыйлаштыру объектының социаль-икътисадый әһәмияте;

объектның тармак үзенчәлекләре.

3. Дәүләт милкендәге предприятиеләрне мөлкәти комплекс буларак сату, шулай ук хуҗалык җәмгыятьләре (ширкәтләре) устав капиталының 50 процентын һәм аннан да күбрәген тәшкил итүче дәүләт милкендәге өлешләрен, пайларын, акцияләрен сату конкурс буенча яисә аукционда гамәлгә ашырыла.

4. Әгәр башка законнарда бүтән тәртип билгеләнмәгән булса, коммерция банкларының дәүләт өлешләрен (пайларын, акцияләрен) хосусыйлаштыру әлеге Законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру ысулын сайлау турындагы карарны Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы районнарының һәм шәһәрләренең администрацияләре, җирле комитетлар кабул итәргә хокуклы.

<u>14 статья.</u> Арендаланган мөлкәтне сатып алу

Арендага бирелгән, шул исәптән сатып алу хокукы белән бирелгән дәүләт мөлкәтен сатып алу әлеге Закон, шартнамә, хосусыйлаштыру турындагы башка норматив-хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Сатып алу хокукы белән арендалау шартнамәләрендә сатып алу вакытлары йә суммасы, йә тәртибе, йә шартлары билгеләнмә-

гән булса, хезмәт коллективына әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктының 1.1 пунктчасы нигезендә ташламалар биреп, дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру предприятиене ачык акционер җәмгыять итеп үзгәртеп кору юлы белән гамәлгә ашырыла.

15 статья. Дәүләт мөлкәтен сату, шул исәптән конкурс буенча һәм аукционда сату

1. Дәүләт мөлкәтен (предприятиене мөлкәти комплекс буларак кертеп) сату, шул исәптән конкурс буенча һәм аукционда сату тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана торган тиешле нигезләмәләрдә билгеләнә.

2. Аукционда яисә конкурс буенча сатыла торган дәүләт мөлкәтенең башлангыч бәясе бәяләү хакыннан түбән куелмый.

3. Конкурста җиңеп чыгучы инвестиция шартларын үтәмәсә, шулай ук тиешенчә үтәмәсә, шул исәптән мондый шартларны үтәүнең арадагы яисә соңгы вакытларын һәм аларны үтәүнен күләмнәрен бозса, конкурста җиңеп чыгучы тарафыннан сатып алынган хосусыйлаштыру объекты дәүләт милкенә түләүсез аерып алынырга тиеш, ә Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы районнарының һәм шәһәрләренең администрацияләре, җирле комитетлар, Татарстан Республикасы Прокуратурасы органнары дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру буенча алыш-биреш килешүләрен өзү турында, законнар һәм дәүләт мөлкәтен сату-алу шартнамәләре нигезендә зыяннарны түләттерү һәм башка нәтиҗәләр ясау турында суд тәртибендә дәгъвалар белдерергә (эш ачарга) тиешләр.

16 статья. Хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен сату

Хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыятьләрнең акцияләре шул җәмгыятьләрнең хезмәткәрләренә ябык язылу буенча сатыла.

Хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыятьләрнең акцияләренә ябык язылу Дәүләт комитеты тарафыннан раслана торган нигезләмә буенча гамәлгә ашырыла.

Хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыять-

ләрнең акцияләрен башка затларга сату тәртибе законнар белән билгеләнә.

17 статья. Дәүләт (республика һәм коммуналь) предприятиеләрен хуҗалык җәмгыятьләре итеп үзгәртеп кору

1. Мөлкәте дәүләт милкендә булган предприятиене үзгәртеп кору нәтиҗәсендә төзелүче ачык акционер җәмгыятьнең гамәлгә куючылары Дәүләт комитеты, җирле комитетлар булалар.

2. Хуҗалык җәмгыятен хосусыйлаштыру планы Дәүләт комитеты (җирле комитет) тарафыннан раслана, анда дәүләткә караган акцияләрне (өлешләрне, пайларны) сату тәртибе һәм шартлары билгеләнә.

Хосусыйлаштыру барышында барлыкка килүче хуҗалык җәмгыятенең устав капиталы күләме аның Дәүләт комитеты тарафыннан расланган бәяләү хакы нигезендә законнар буенча билгеләнә.

3. Хезмәт коллективы әгъзалары тарафыннан сатып алынмаган акцияләр (өлешләр, пайлар) дәүләт милкендә кала йә законнарда билгеләнгән тәртиптә сатыла.

4. Хуҗалык җәмгыятенең өлешләрен (пайларын) бүлү Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

18 статья. Дәүләт (республика һәм коммуналь) унитар предприятиеләрен акцияләренең 100 проценты да дәүләт милкендә булган ачык акционер җәмгыятьләр итеп үзгәртеп кору

Дәүләт предприятиеләрен акцияләренең 100 проценты да дәүләт милкендә булган ачык акционер җәмгыятьләр итеп үзгәртеп кору законнар нигезендә башкарыла.

19 статья. Дәүләт мөлкәтен кертем сыйфатында хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталына кертү

Дәүләт мөлкәтен кертем сыйфатында хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталына кертү законнарда каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы районнарының

һәм шәһәрләренең администрацияләре, җирле комитетлар карары буенча гамәлгә ашырыла.

20 статья. Хосусыйлаштыру шартлары

1. Хосусыйлаштыру планында, хосусыйлаштырылучы дәүләт мөлкәтен сату-алу шартнамәсендә дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның социаль, инвестиция һәм башка шартлары каралырга мөмкин.

Хосусыйлаштыру объектына карата социаль шартларда түбәндәгеләр күздә тотылырга мөмкин:

эш урыннарының билгеле бер санын саклау яисә өстәмә эш урыннары булдыру;

хезмәткәрләрне яңа һөнәргә өйрәтү яисә аларның белгечлекләрен күтәрү;

хезмәтне саклауның гамәлдәге системасын һәм хезмәткәрләрнең сәламәтлеген саклау;

халыкка социаль-мәдәни, коммуналь-көнкүреш яисә транспорт хезмәте күрсәтү объектларының эшчәнлеге юнәлешен үзгәртүне яисә алардан файдалануны туктатуны чикләү;

әйләнә-тирә мохитне һәм гражданнарның сәламәтлеген саклау буенча махсус гамәлләрне тормышка ашыру.

Инвестиция шартларында һәм башка шартларда түбәндәгеләр күздә тотылырга мөмкин:

хосусыйлаштыру объектын реконструкцияләү, аерым төрдәге җиһазлар сатып алу, җитештерүне модернизацияләү һәм киңәйтү гамәлләрен башкару;

оешманың юнәлешен, чыгарыла торган продукциянең номенклатурасын һәм аны җитештерүнең минималь күләмнәрен саклау;

Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнүче куллланучыларга продукция китереп тору.

Кабул ителгән йөкләмәләрне бозган әчен якларга законнарда һәм шартнамәдә каралган җаваплылык билгеләнә.

2. Дәүләт предприятиесен хосусыйлаштыру барышында башка юридик зат итеп үзгәрткәндә, әлеге юридик зат үзгәртеп корылучы оешманың хокукларын ала һәм законнарда каралган чикләрдә тиешле хокукларга һәм йөкләмәләргә, шул исәптән җирдән һәм башка табигый байлыклардан файдалану хокукына ия була.

3. Хосусыйлаштырылучы дәүләт предприятиеләре тарафыннан башка хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең устав (туплан-ма) капиталларына кертелгән акцияләр (өлешләр, пайлар) шуларның мөлкәтләре составында хосусыйлаштырылалар яисә Дәүләт комитеты (җирле комитет) карары буенча республика милкендә (коммуналь милектә) калалар.

4. Предприятиеләрне хосусыйлаштырганда әйләнә-тирә мохитне саклау өчен куелган корылмалар, җайланмалар, җиһазлар хосусыйлаштыру объекты белән бүленмәс бер бөтен дип танылалар.

<u>21 статья.</u> Хосусыйлаштыру буенча алыш-биреш килешүләрен рәсмиләштерү

1. Хосусыйлаштыру ысулының нинди булуына карамастан, дәүләт мөлкәтен сатучы белән сатып алучы арасында законнарда каралган тәртиптә шартнамә төзелә.

2. Дәүләт мөлкәтен сату-алу шартнамәсенең катгый шартларына түбәндәгеләр керә:

мөлкәтне сатучы һәм сатып алучы турында белешмәләр, хосусыйлаштыру объектының исеме һәм аның урнашкан урыны, мөлкәтнең составы һәм хакы, җир кишәрлегенә хокуклар алу шартлары; ачык акционер җәмгыятьләренең акцияләре саны; аларның категорияләре (тибы) һәм хакы (ширкәттәге пай күләме, җәмгыятьтәге өлеш күләме); хосусыйлаштыру объектын сатып алучы милкенә тапшыру тәртибе; сатып алынган мөлкәт өчен түләү рәвеше һәм вакытлары; мөлкәт сатып алучының аннан файдалану буенча йөкләмәләре; мөлкәт сатып алынганда сатып алу нигезләнеп эш иткән инвестиция шартлары, социаль яисә башка шартлар; инвестиция шартларын һәм социаль шартларны сатып алучы тарафыннан раслау тәртибе;

инвестиция шартларын һәм (яисә) социаль шартларны тәэмин итү ысуллары, шул исәптән аларны үтәү гарантияләре;

күрсәтелгән мөлкәтне биләү хокукларын һәм алардан файдалану хокукларын сатып алучы тарафыннан аңа шушы мөлкәткә милекчелек хокукы күчкәнгә кадәр гамәлгә ашыру тәртибе.

Сатып алучының хосусыйлаштыру объектына карата барлык йөкләмәләренең үтәлү вакытлары, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә билгеләнә торган хак бәясе булырга тиеш.

3. Сатып алучыда хосусыйлаштырылган мөлкәткә милекчелек хокукы законда билгеләнгән тәртиптә барлыкка килә.

Сатып алучыда хосусыйлаштыру таныклыгы булганда хосусыйлаштыру буенча алыш-биреш гамәлләрен дәүләт теркәвенә алу тормышка ашырыла.

## III бүлек. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру барышында финанс мөнәсәбәтләре

### 22 статья. Дәүләт мөлкәтенең хакын билгеләү

1. Дәүләт мөлкәтенең хакын билгеләү Дәүләт комитеты тарафыннан әзерләнүче һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланучы норматив-хокукый актлар нигезендә башкарыла.

2. Бәяләнүче мөлкәт составына тәп һәм әйләнештәге средстволар, шулай ук бәяләре оешманың мөстәкыйль балансында чагыла торган башка кыйммәтләр (финанс активлары, төзелеп бетмәгән объектлар һәм башкалар) керә. Предприятиенең бәяләү хакын билгеләгәндә аның финанс һәм икътисадый хәле, җитештерүнең табышлылыгы, интеллектуаль эшчәнлеге нәтиҗәләренә хокукы, җитештерелә торган продукциягә ихтыяҗ, үсеш перспективалары, дөньякүләм бәяләр дәрәҗәсе һәм башка факторлар исәпкә алына.

### 23 статья. Дәүләт мөлкәтен һәм аларның чыганакларын сатып алу өчен түләү чаралары

1. Татарстан Республикасының Республика бюджеты, җирле бюджет ассигнованиеләре, шулай ук дәүләт милкендәге башка чыганаклар хосусыйлаштырылучы мөлкәтне сатып алу әчен файдаланыла алмыйлар.

2. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырганда Россия Федерациясенең акча берәмлеге (валютасы) законлы түләү чаралары булып таныла.

24 статья. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырганда түләү тәртибе

1. Сатып алына торган мөлкәт өчен бер мәртәбә яисә өлешләп түләргә мөмкин. Дәүләт мөлкәте өчен өлешләп түләү тәртибен Дәүләт комитеты яисә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланучы нигезләмә нигезендә җирле комитетлар билгели.

2. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырганда түләү тәртибе сатучы белән сатып алучы арасындагы шартнамә белән билгеләнә.

25 статья. Хосусыйлаштырудан керә торган акчаларны бүлү. Хосусыйлаштыру фонды

1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырудан алынган акчалар Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә торган нормативлар буенча Татарстан Республикасының Республика бюджеты һәм җирле бюджетлары, тиешле хосусыйлаштыру фондлары арасында бүленергә, барлык төр салымнардан азат ителергә тиеш.

2. Фонд юридик зат була. Аның эшчәнлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый торган устав белән регламентлаштырыла.

3. Фонд акчалары түбәндәгеләр хисабына хасил була:

дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырудан килгән керемнәр;

банкларның һәм башка кредиторларның кредитлары;

дәүләт мөлкәтеннән файдаланудан, шул исәптән аренда түләвеннән, шулай ук девидендлардан килгән табыш;

законнарда тыелмаган башка чыганаклар.

4. Фонд акчалары түбәндәгеләр өчен файдаланыла:

хосусыйлаштырылучы оешмаларны кабат инвестицияләү, аларны техник яктан яңадан җиһазландыру һәм аларга хосусыйлаштырудан соң ярдәм итү;

хосусыйлаштырылучы оешмаларга кредитлар буенча гарантияләр бирү;

эшкуарлыкка ярдәм итү; фәнни-техник, аналитик, социологик һәм башка тикшеренүләрне, хосусыйлаштыру өлкәсендә законнар һәм норматив актлар проектларын эшләүне финанслау;

консультант һәм эксперт хезмәтләре күрсәткән өчен түләү;

фондларның эшчәнлеген финанслау;

кыйммәтле кәгазьләр базары үсеше, депозитар эшчәнлек һәм теркәү эшчәнлеге;

әлеге законны һәм Дәүләт программасын тормышка ашыруга юнәлдерелгән башка гамәлләр өчен.

5. Коммуналь мөлкәтне хосусыйлаштырудан алынган акчалар, шулай ук дивидендлар, аренда түләве - шәһәрләрнең (районнарның) хосусыйлаштыру фондларында, ә алар булмаганда, җирле комитетларның махсус счетларында туплана.

## IV бүлек. Хосусыйлаштыруның социаль мәсьәләләре

### 26 статья. Хосусыйлаштырылганда бирелә торган өстенлекле ташламалар

1. Дәүләт комитеты (җирле комитет) карары буенча хезмәт коллективы фикерен исәпкә алып хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен сатканда өстенлекле ташламалар бирүнең түбәндәге вариантларның берсе кулланыла:

Хосусыйлаштырыла торган предприятиенең хезмәт коллективы әгъзаларына 20 процентка кадәр гади (тавышка куелучы) акцияләрне аларның номиналь бәясеннән 10нан алып 50 процентка кадәр ташлама ясап бер елга кадәр беренче чиратта алу хокукы бирелә, бу очракта ул башлангыч кертем акцияләрнең номиналь бәясеннән 20 проценттан да ким булмаска тиеш.

Бер хезмәткәргә туры килә торган өстенлекле ташламалар суммасы Дәүләт комитеты (җирле комитетлар) хосусыйлаштыру планын раслаган көндә булган Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән 5 минималь хезмәт хакы күләменнән, ә сатып алына торган акцияләрнең гомуми номиналь күләме хосусыйлаштыру планын раслаган көнгә Татарстан Республикасында билгеләнгән 50 минималь хезмәт хакы күләменнән артмаска тиеш.

Хосусыйлаштырыла торган предприятиеләр администрацияләренең урындагы затларына (җитәкчегә, аның урынбасарларына, баш инженерга, баш белгечләргә, баш хисапчыга һәм хезмәт коллективы карары буенча структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренә) гади акцияләр сатып алу хокукы бирелә, аларның номиналь бәясе барлык күрсәтелгән урындагы затларга акционер җәмгыять устав ка-

питалы күләменең 5 процентына кадәр билгеләнә, әмма акцияләрне сатып алуга катнашучы барлык урындагы затларга Татарстан Республикасында билгеләнгән 2500 минималь хезмәт хакы күләменнән артмаска тиеш.

Предприятие хезмәткәрләре төркеменә, физик һәм юридик затларга төзелгән шартнамә шартлары нигезендә устав капиталының 30 процентына кадәр ташлама белән 30 процент акция сатып алу хокукы (опцион) бирелә, төзелгән шартнамәнең гамәлдә булу вакыты 18 айдан да артмаска тиеш.

Күрсәтелгән төркемгә, физик яисә юридик затларга шартнамә гамәлдә булган чорда опцион тәртибендә бирелә торган гади акцияләрне тавышка кую хокукы бирелә.

Шартнамәдә якларның йөкләмәләре һәм аларны тәэмин итү ысуллары билгеләнә.

Хосусыйлаштырыла торган предприятиенең хезмәт коллективы әгъзаларына гади акцияләр сатыла, алар һәр эшләүчегә хосусыйлаштыру планын раслаган көнгә Татарстан Республикасында билгеләнгән 20 минималь хезмәт хакы күләменнән артмаган суммада устав капиталының 20 процентына кадәр билгеләнә, номиналь бәясеннән 30 процентка кадәр ташлама белән бер елга кадәр өлешләп түләү нигезендә булырга тиеш.

Аерым предприятиеләргә башка өстенлекле ташламалар да бирелергә мөмкин.

2. Предприятиене тулысынча яисә өлешләп хосусыйлаштырганда предприятиедә эшләүчеләргә бирелә торган өстенлекле ташламалар шулай ук түбәндәгеләргә дә кагыла:

әлеге предприятиедә эшләп пенсиягә чыккан, шул исәптән инвалидлык буенча, хезмәттә имгәнү яисә һөнәри авыру нәтиҗәсендә пенсиягә чыккан затларга;

хезмәт турындагы законнар нигезендә элек эшләгән эш урынына кире кайту хокукы булган затларга, үз теләкләре буенча, күчерү тәртибендә, штатны яисә эшләүчеләр санын кыскарту сәбәпле эштән азат ителгән һәм әлеге предприятиедә кимендә 10 ел эш стажы булган ир-атларга һәм 7 ел да 6 ай эш стажы булган хатын-кызларга;

әлеге предприятиедә эшләп һәлак булган хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларына.

3. Предприятиедәге хезмәт коллективының акцияләр һәм башка мөлкәт сатып алуга хокуклы әгъзалары исемлеге Дәүләт комитеты (җирле комитет) хосусыйлаштыруны сорап язган гаризаны

теркәгән көнгә төзелә. Хезмәт коллективының гомуми җыелышы (конференциясе) карары буенча һәм Дәүләт комитеты (җирле комитет) ризалыгы белән исемлеккә предприятиене хосусыйлаштыруны сорап язган гаризаны теркәгәннән соң һәм хосусыйлаштырылган предприятиене теркәгәнче эшкә урнашкан затлар да законнар нигезендә кертелергә мөмкин.

27 статья. Хосусыйлаштыру шартларында хезмәткәрләр өчен гарантияләр

1. Хосусыйлаштыру барышында төзелгән оешмалар хосусыйлаштыруга кадәр барлыкка килгән хезмәт мөнәсәбәтләреннән килеп чыга торган йөкләмәләрен үтиләр һәм яңа күмәк шартнамә төзелгәнгә кадәр алар буенча җаваплы булалар.

2. Әгәр хезмәт коллективы үзе хәл итсә, хосусыйлаштыру барышында барлыкка килгән оешмалар, теркәлгәннән соң алты айдан да соңга калмыйча, аның җитәкчесе хезмәт коллективы белән яңа күмәк шартнамә төзергә яисә элеккесенең гамәлдә булуын озайтырга тиеш.

3. Хосусыйлаштырылган оешмаларның хезмәткәрләрен эшкә урнаштыру һәм эштән азат итү (шул исәптән гарантияләр, ташламалар һәм компенсацияләр бирү) хезмәт турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Хосусыйлаштырылучы оешмалардагы хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклау максатында дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруга хезмәт коллективы гаризасын теркәгән мизгелдән һәм хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә төзелгән акционер җәмгыятьләрне дәүләт теркәве мизгеленә кадәр Дәүләт комитеты (җирле комитетлар) ризалыгыннан тыш түбәндәгеләрне эшләү тыела: оешманы үзгәртеп корырга, бетерергә һәм аның оештыру структурасын үзгәртергә, хосусыйлаштырылучы оешмалар били торган биналар, корылмалар, тәзелмәләрнең элек төзелгән аренда шартнамәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә, аларның гамәлдә булуын туктатырга. Әлеге чорда оешманың штат расписаниесен үзгәртү, эштән азат итү (үз теләге белән һәм башка эшкә күчү тәртибендә эштән азат итү, хезмәт бурычларын үтәү мөмкин булмаган авыру аркасында мөмкин булмаган очраклардан гайре) һәм хезмәт коллективы яисә аның вәкиллекле органы ризалыгыннан башка эшләүчеләрнең санын кыс-

карту тыела.

## V бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

<u>28 статья.</u> Хосусыйлаштыру буенча алыш-бирешләрнең гамәлгә яраксыз булуы

1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру буенча алыш-биреш килешүләре түбәндәге очракларда гамәлгә яраксыз дип таныла:

әлеге Законның, башка норматив-хокукый актларның дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибен билгели торган нигезләмәләрен бозу;

дәүләт мөлкәтен сатып алырга хокукы булмаган зат тарафыннан аны сатып алу;

хосусыйлаштырганда түләүнең законсыз чараларын куллану;

мөлкәтне сатучы белән сатып алучы арасында сүз куешу, шул исәптән шушы мөлкәтнең бәясен киметү хакында да;

сатып алучыга башка сатып алучылар белән чагыштырганда законнарда каралмаган ташламалар һәм өстенлекләр бирелү;

законнарда каралган башка нигезләр.

2. Хосусыйлаштыру буенча алыш-биреш килешүләрен гамәлгә яраксыз дип тану турындагы бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә суд яисә арбитраж суд тарафыннан карала.

3. Әлеге Законда билгеләнгән ысуллардан аермалы башка ысуллар белән дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру рөхсәт ителми, ә дәүләт мөлкәтен шундый ысуллар белән хосусыйлаштыру буенча алыш-биреш килешүләре төзелгән мизгелдән гамәлгә яраксыз дип таныла һәм хокукый нәтиҗәләргә китерми.

Дәүләт мөлкәтенең хак бәясе күрсәтелмәгән дәүләт мөлкәтен сату-алу шартнамәләре аларны төзегән мизгелдән әһәмиятсез дип танылалар һәм алар хокукый нәтиҗәләргә китермиләр.

<u>29 статья.</u> Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык

1. Әлеге Законны бозуда гаепле юридик һәм физик затлар законнар нигезендә юридик җаваплы булалар.

Хосусыйлаштыру турындагы законнарны бозып, хокукка каршы гамәлләр кылу нәтиҗәсендә китерелгән зыян законнарда билгелән-

гән тәртиптә түләттерелергә тиеш.

2. Дәүләт комитеты (җирле комитетлар), дәүләтнең башка органнары законнар белән үз компетенцияләренә кертелгән мәсьәләләр буенча түбәндәгеләргә хокуклы:

дәгъвачы һәм җавап тотучы буларак, судта, арбитраж судта чыгыш ясарга;

җинаять эшләре кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен прокуратура органнарына материаллар җибәрергә.

Дәүләт комитеты һәм җирле комитетлар үз компетенцияләренә кертелгән мәсьәләләр буенча судка, арбитраж судка мөрәҗәгать иткәндә дәүләт пошлинасын түләүдән азат ителәләр.

<u>30 статья.</u> Йомгаклау нигезләмәләре

Әлеге Закон үз көченә кергәнче чыгарырга дип хәл ителгән ачык акционер җәмгыятьләрне хосусыйлаштыру барышында барлыкка килгән "алтын акцияләр"не Татарстан Республикасының күрсәтелгән җәмгыятьләр белән идарә итүдә катнашуына әлеге Законда каралган махсус хокукы ("алтын акция") дип санарга".

<u>2 статья.</u> Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш;

Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары тарафыннан үзләренең әлеге Законга каршы килә торган норматив-хокукый актларын карап чыгуларын һәм юкка чыгаруларын тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 27 мае
№ 1559